КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 ноябрь г.Казань № 1096

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алу белән бәйле гражданнарга өстәмә бер тапкыр акчалата түләү турында» 2017 ел, 13 июль, 493 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алу белән бәйле гражданнарга өстәмә бер тапкыр акчалата түләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алу белән бәйле гражданнарга өстәмә бер тапкыр акчалата түләү турында» 2017 ел, 13 июль, 493 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алу белән бәйле гражданнарга өстәмә бер тапкыр акчалата түләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктта:

2 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза бирүче граждан хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелгән уллыкка алу турындагы таныклыкны күрсәтергә хокуклы.»;

түбәндәге эчтәлекле 81 пункт өстәргә:

«8[1]. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә түбәндәге мәгълүматларны соратып ала:

уллыкка алу турындагы суд карары закон көченә кергән датага баланың инвалидлыгын билгеләү фактын раслый торган (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында (Граждан хәле актларын теркәү идарәсеннән).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин